**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 21 июль № 494

г. Казань

Тиешле территориядә теркәлгән этләр саныннан чыгып, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә этләрне йөртү өчен урыннар булдыру зарурлыгын билгеләүнең тәкъдим ителә торган критерийларын раслау турында

«Татарстан Республикасында йорт хайваннарын тотуның аерым мәсьәләләре турында» 2014 ел, 6 март, ТРЗ-16 нчы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Тиешле территориядә теркәлгән этләр саныннан чыгып, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә этләрне йөртү өчен урыннар булдыру зарурлыгын билгеләүнең тәкъдим ителә торган критерийларын (алга таба – тәкъдим ителә торган критерийлар) расларга (карарга теркәлә).

2. Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына этләрне йөртү өчен урыннар булдыру зарурлыгын билгеләгәндә Тәкъдим ителә торган критерийларга таянып эш итүне тәкъдим итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2016\494.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 21 июль, 494 нче карары белән расланды

Тиешле территориядә теркәлгән этләр санынннан чыгып,
Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә этләрне йөртү өчен урыннар булдыру зарурлыгын билгеләүнең тәкъдим ителә торган критерийлары

1. Этләрне йөртү өчен урыннар 100 гектардан алып 150 гектарга кадәр мәйданлы микрорайон, торак район территориясендә, анда теркәлгән этләр санынннан чыгып, түбәндәге критерий нигезендә булдырыла:

| Теркәлгән этләр саны, берәмлек | Этләрне йөртү урыннарының гомуми мәйданы, кв.метр | Минималь рөхсәт ителгән зурлыктагы мәйданнар саны, кимендә |
|---|---|---|
| 10 нан 50 гә кадәр | 90 – 450 | 1 |
| 50 дән 100 гә кадәр | 450 – 900 | 5 |
| 100 дән 200 гә кадәр | 900 – 1800 | 10 |
| 200 дән 400 гә кадәр | 1800 – 3600 | 20 |
| 400 дән 600 гә кадәр | 3600 – 5400 | 40 |

2. Этләрне йөртү өчен урыннар булдырганда түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

микрорайонның һәм торак районның яшел утыртмалар булмаган гомуми файдаланудагы территориясен сайларга;

бер мәйданчыкның минималь рөхсәт ителгән зурлыгын 90 кв.метр алырга;

мәйданчыкта кимендә 1,5 метр биеклектәге киртә коруны һәм киртә артында периметр буйлап яшелләндерүне күздә тотарга;

мәйданчыкларны торак һәм иҗтимагый биналарның тәрәзәләреннән кимендә 40 метр ераклыкта урнаштырырга;

чүп савытлары, яктырту һәм этләрне йөртү урынынннан файдалану кагыйдәләре белән мәгълүмати стенд булдыруны күздә тотарга.

_______________________________